**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **с. Тюлячи** **БОЕРЫК**

«16» декабрь 2022 № 278

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 28 октябрендәге 270 номерлы «2019-2020 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Юность» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә бәяләрнең прейскурантын раслау турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә,

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 28 октябрендәге 270 номерлы «2019-2020 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Юность» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә бәяләрнең прейскурантын раслау турында» боерыгына (12.11.2020 № 214, 14.09.2022 № 185, 10.10.2022 № 228 боерыклар редакциясендә), 2022-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Юность» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә түләүле хезмәт күрсәтүләргә бәяләр прейскурантын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

2022-2023 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы «Юность» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә түләүле хезмәт күрсәтүләргә бәяләр прейскуранты

1. Күмәк шуу:

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Категория | Вакыты | Бәя |
|---|---|---|---|
| | 5 яшькә кадәр балалар | 1 сәгать | Түләүсез |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Тимераяклар алмыйча күмәк шуу (шәхси тимераяклар белән) | 14 яшькә кадәр ятим балалар | 1 сәгать | Түләүсез |
| | Инвалидлыгы булган балалар | 1 сәгать | Түләүсез |
| | 5 яшьтән 14 яшькә кадәр балалар | 1 сәгать | 50 сум |
| | Пенсионерлар | 1 сәгать | 50 сум |
| | Инвалидлыгы булган өлкәннәр | 1 сәгать | 50 сум |
| | Күпбалалы гаиләләр әгъзалары | 1 сәгать | 50 сум |
| | Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның балалары | 1 сәгать | Түләүсез |
| | Халыкның башка категорияләре | 1 сәгать | 100 сум |
| Тимераякларны вакытлыча куллануга алып тору | 14 яшькә кадәр балалар | 1 сәгать | 100 сум |
| | 14 яшькә кадәр ятим балалар | 1 сәгать | 50 сум |
| | Инвалидлыгы булган балалар | 1 сәгать | 50 сум |
| | Күпбалалы гаиләләр әгъзалары | 1 сәгать | 50 сум |
| | Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның балалары | 1 сәгать | Түләүсез |
| | Пенсионерлар | 1 сәгать | 100 сум |
| | Халыкның башка категорияләре | 1 сәгать | 150 сум (абонемент сатып алганда 10 баруга 1200 сум) |

Искәрмә: ташламалар таныклыклар күрсәткәндә бирелә.

2. Боз шугалагын арендалау:

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Бәя |
|---|---|
| Боз шугалагын арендалау (1 сәгать) | 3000 сум |

3. Башка хезмәтләр:

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Категория | Бәя |
|---|---|---|
| Тимераякларны кайрау (1 пар) | Халыкның барлык категорияләре өчен | 150 сум |
| Хоккей киемендә иректе уен | 16+ категориясе өчен | Бер кешегә 150 сум Уенчылар саны 10 кешедән артык булганда хезмәт күрсәтү «Боз шугалагын арендалау» хезмәте буенча һәм әлеге прейскурант нигезендә башкарыла |

Искәрмә: санап чыгу буенча түләү мөмкинлеге. Ташламалар раслаучы таныклыкны, гаилә әгъзасын мобилизация буенча Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә чакыру турында хәрби комиссариатның белешмәсен, башка дәүләт органнары документларын раслый торган белешмәсен күрсәткәндә бирелә.».

2. Әлеге боерык 2022 елның 10 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев